КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 24 август г.Казань № 1013

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 ел, 12 ноябрь, 622 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 ел, 12 ноябрь, 622 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 10 декабрь, 706 нчы; 2007 ел, 29 декабрь, 800 нче; 2009 ел, 23 гыйнвар, 35 нче; 2009 ел, 11 декабрь, 849 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 31 гыйнвар, 56 нчы; 2011 ел, 5 март, 177 нче; 2011 ел, 18 ноябрь, 947 нче; 2012 ел, 19 июнь, 524 нче; 2012 ел, 5 октябрь, 833 нче; 2013 ел, 19 ноябрь, 893 нче; 2014 ел, 21 апрель, 262 нче; 2014 ел, 9 сентябрь, 656 нчы; 2014 ел, 24 декабрь, 1018 нче; 2015 ел, 4 июнь, 409 нчы; 2015 ел, 7 август, 575 нче; 2016 ел, 3 июнь, 370 нче; 2017 ел, 20 апрель, 232 нче; 2017 ел, 26 сентябрь, 719 нчы; 2018 ел, 27 сентябрь, 869 нчы; 2018 ел, 10 декабрь, 1100 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1295 нче; 2020 ел, 27 май, 426 нчы; 2020 ел, 1 сентябрь, 770 нче; 2020 ел, 12 ноябрь, 1019 нчы; 2021 ел, 20 март, 153 нче; 2021 ел, 20 июль, 618 нче; 2021 ел, 10 август, 699 нчы; 2021 ел, 27 декабрь, 1295 нче; 2022 ел, 11 март, 216 нчы; 2022 ел, 2 ноябрь, 1168 нче; 2022 ел, 26 декабрь, 1416 нчы; 2023 ел, 16 март, 255 нче; 2023 ел, 16 июнь, 721 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе турында» 2006 елның 28 ноябрендәге ПУ-505 номерлы Указы һәм Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары системасы һәм структурасы турында» 2023 елның 4 маендагы 276 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

5, 6, 8 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе турындагы нигезләмәдә:

1.5 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 пунктта «предприятиеләр, учреждениеләр һәм башка» сүзләрен төшереп калдырырга;

«*» астөшермәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«* Код билгеләнеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2023 ел, 26 июнь, 752 нче карары белән расланган Республика башкарма хакимият органнарының дәүләт идарәсе функцияләре кодификаторы буенча.»;

3.3 пунктта:

3.3.5 пунктчада «кертә» сүзләре алдына «Татарстан Республикасы Рәисенә,» сүзләрен өстәргә;

3.3.11 пунктчада «министрлыклар, ведомстволар» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

4.1 пунктның 4.1.6 пунктчасында «башкарма хакимият органнарыннан» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарыннан» сүзләренә алмаштырырга;

5.3 пунктның дүртенче абзацында татар текстында «үтәү өчен» сүзләреннән соң «һәм Инспекция тарафыннан кабул ителә торган хокукый актларның һәм аның тарафыннан гамәлгә ашырыла торган оештыру һәм боерык бирү характерындагы гамәлләрнең законлылыгы өчен» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин